СОВЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная , д. 200, с.Качелино,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366)52-3-93, факс (84366)52-3-93. E-mail: Kach.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**«22» март 2024 ел** **№ 3**

**"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Кәче авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 24 ноябрендәге 3 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Кәче авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Кәче авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Кәче авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 нче елның 24 ноябрендәге 3 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Кәче авылында гражданнар җыенының беренче этабын Кәче авылы, Үзәк урам, 200 йорты адресы буенча 2024 елның 05 нче апреленә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Кәче авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 нче елның 24 ноябрендәге 3 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Кәче авылында гражданнар җыенының икенче этабын Кәче авылы, Үзәк урам, 200 йорты адресы буенча 2024 елның 05 нче апреленә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Кәче авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 нче елның 24 ноябрендәге 3 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Кәче авылында гражданнар җыенының өченче этабын Кәче авылы, Үзәк урам, 200 йорты адресы буенча 2024 елның 05 нче апреленә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Авангард, Күлле, Пионер, Күпер, Тау асты урамында яшәүчеләр

2нче этап: Яшьләр, Комсомол, Җиңүнең 65 еллыгы, Тынычлык урамында яшәүчеләр.

3нче этап: Үзәк, Сәйдәш, Хезмәт, Болынлык, Тау өсте, Чокырлы, Бакчалы урамында яшәүчеләр

5. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Кәче авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт чиктәрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү,төзекләндерү, карап тоту (Кәче авылының Тау асты урамы 207 нче йорттан, Болынлык урамына кадәр юл-урам челтәрендәге автомобиль юлларын вак таш белән тигезләү; Кәче авылы урам челтәренең юл полотнасы чокырларын ямау, Үзәк урам 121 нче а йорттан 203 нче йортка кадәр; Бакча урамы)?»

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

6. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Чулпан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 24 нче ноябрендәге 3 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны халык күп җыела торган урында мәгълүмат стендында ТР, Арча районы, Кәче авылы, Үзәк урамы, 200 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кәче авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Гәрәев